ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

19.12.2018 Казан ш. № 5-105/тэ

«Көнбатыштан чыгучы җылылык челтәрләре» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан күрсәтелүче җылылык энергиясе тапшыру хезмәтләренә 2019-2021 елларга тарифлар билгеләү хакында

«Җылы белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Көнбатыштан чыгучы җылылык челтәрләре» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан күрсәтелүче җылылык энергиясен тапшыру хезмәтләренә, шушы карарның 1 нче кушымтасына туры китереп, календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Шушы карарның 1 нче пунктында билгеләнгән тарифлар 2019 елның 1 гыйнварыннан башлап 2021 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Шушы карарның 2 нче кушымтасы нигезендә 2019-2021 елларга, билгеләнгән тарифларны индексацияләү ысулыннан файдаланып, тарифлар формалаштыру өчен җайга салуның озак сроклы чорына билгеләнә торган җайга салуның озак сроклы параметрларын билгеләргә.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 19.12.2018№ 5-105/тэ карарына 1 нче кушымта

«Көнбатыштан чыгучы җылылык челтәрләре» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан күрсәтелүче җылылык энергиясе тапшыру хезмәтләренә 2019-2021 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

<table>
<tr><th rowspan="2">№ п/п</th><th rowspan="2">Муниципаль берәмлекнең, җайга салынучы оешманың аталышы</th><th rowspan="2">Тариф төре</th><th rowspan="2">Ел</th><th colspan="2">Җылылык энергиясен тапшыру матдәсенең төре</th></tr>
<tr><th>Су</th><th>Пар</th></tr>
<tr><td></td><td colspan="5">Яр Чаллы шәһәре</td></tr>
<tr><td rowspan="7">1</td><td rowspan="7">«Көнбатыштан чыгаручы җылылык челтәрләре» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте</td><td colspan="4">Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгәндә, – кулланучылар өчен</td></tr>
<tr><td rowspan="6">Бер ставкалы, сум/Гкал</td><td>01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр</td><td>1731,24</td><td>-</td></tr>
<tr><td>01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр</td><td>1867,84</td><td>-</td></tr>
<tr><td>01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр</td><td>1867,84</td><td>-</td></tr>
<tr><td>01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр</td><td>1829,18</td><td>-</td></tr>
<tr><td>01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр</td><td>1829,18</td><td>-</td></tr>
<tr><td>01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр</td><td>2016,53</td><td>-</td></tr>
</table>

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 19.12.2018№ 5-105/тэ карарына 2 нче кушымта

Билгеләнгән тарифларны индексацияләү ысулыннан файдаланып тарифлар формалаштыру өчен 2019-2021 елларга җайга салуның озак сроклы чорына билгеләнә торган җайга салуның озак сроклы параметрлары

| № п/п | Муниципаль берәмлекнең, җайга салынучы оешманың аталышы | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Җылылык челтәренең матди сыйфатламасына карата сарыфлар күләме | Технологик сарыфлар |
| | | | мең сум | % | Гкал/м$^2$ | Гкал |
| | Яр Чаллы шәһәре | | | | | |
| 1 | «Көнбатыштан чыгучы җылылык челтәрләре» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | 2019 | 6921,47 | 1 | 1,72 | 12890,76 |
| | | 2020 | X | 1 | 1,72 | 12890,76 |
| | | 2021 | X | 1 | 1,72 | 12890,76 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге